СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 февраль 2023 ел** Болгар ш. **№ 27-1**

2022 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2023 елга бурычлар турында

Спас муниципаль районы Башлыгының 2022 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2023 елга бурычлар турындагы хисабын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Спас муниципаль районы Советы икътисадны, социаль өлкәне тотрыклы үстерү буенча эзлекле эшне билгеләп үтә.

Районның тулай территориаль продукты 7 млрд. 373 млн. сум тәшкил иткән, бу 2022 ел дәрәҗәсеннән 8,5 процентка югарырак. Ашлыкның тулай җыемы 170,5 мең тонна тәшкил итте.

2022 елда бюджетның керем өлеше 879,1,0 млн. сум күләмендә үтәлгән.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Спас муниципаль районы башлыгының хисабы һәм 2023 елга бурычларын игътибарга алырга.
2. 2023 елда Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүне өстенлекле бурычлар дип санарга.
3. 2023 елда Спас муниципаль районы башкарма комитетына тәэмин итәргә:

- район территориясендә милли проектларны үтәү, республика, муниципаль программаларны гамәлгә ашыру;
- кече һәм урта бизнесны үстерү, бюджетның керем өлешен арттыру;
- районда инвестицияләр җәлеп итү эшен активлаштыру;
- җирләрдән һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру.

4. Районның авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү программаларында катнашуга халыкны җәлеп итү буенча максатчан эш алып барырга;

- Авыл торак пунктларын төзекләндерү буенча актив эшләргә.

5. Район Советы Аппаратына Спас муниципаль районы Советының хисап сессиясендә, район халкы белән очрашуларда әйтелгән кисәтүләр һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерергә.

6. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башлыгының хисабын Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Спас муниципаль районы башлыгы,
Советы рәисе Ф.В. Мөхәммәтов